# Тема:

# Башлангыч сыйныфларда коммуникатив эшчәнлек

# Заман таләбе

- Яңа заман укучыдан белем таба һәм аны куллана алуны, эш-гамәл башкара алу осталыгына ия булуны, башкалар белән яши белүне һәм үз-үзеңне үстерә алуны сорый.
- Мәгариф системасындагы яңалыкларны гамәлгә ашыруда төп көч вазифасын үтәү өчен икенче буын дәүләт стандартлары төзелде.

# Метапредмет ысуллар

- **Белем алу** укучының танып-белү, универсал белем туплау эшчәнлегеннән гыйбарәт.
- Универсал уку эшчәнлеге үзе дүрт блокны - шәхси, регулятив, танып-белү һәм коммуникатив блокларны берләштерә.

# Коммуникатив эшчәнлек

укучының тыңлый, ишетә, үз фикерен диалогта һәм монологта башкаларга җиткерә белү күнекмәләрен үстерү өчен юнәлдерелгән.
Төп максат — укучыларда **коммуникатив компетенция** (аралашу осталыгы) формалаштыру.

# Сөйләм теленә өйрәтүнең төп максатлары:

**1) гамәли максат,** ягъни татар теленең(рус теленең) фонетик, лексик, грамматик берәмлекләрен гамәли үзләштерүгә ирешү һәм укучыларның сөйләм күнекмәләрен үстерү;

2) **гомуми белем бирү максаты** — укучыларның акыл эшчәнлеген активлаштыру, логик фикерләү сәләтен камилләштерү, сөйләм культурасын үстерү;

3) **тәрбияви максат** — балаларның рухи дөньясын баету, аларда шәхесара һәм мәдәниятара аралашу күнекмәләре булдыру, төрле милләт вәкилләре арасында дуслык һәм хөрмәт хисләре тәрбияләү.

# Максатка ирешү юллары

- Гомуми белем бирү һәм тәрбияви максатларга ирешү өчен, укучыларның акыл хезмәте күнекмәләрен үстерү, сөйләм этикеты үрнәкләрен урынлы кулланырга өйрәтү, шул исәптән үз халкыңның гореф-гадәтләре, милли бәйрәмнәре, халык авыз иҗаты үрнәкләре белән таныштыру сорала.

# Аралашу осталыгын үстерү

- Укучыларның аралашу осталыгы дәресләрдә генә түгел, ә сыйныфтан тыш чараларда да үстерелә.
- Моның өчен иң яхшы шигырь сөйләүче яки иң яхшы җыр башкаручыга, иң яхшы рәсем ясаучы яки иң яхшы инша язучыга конкурслар, төрле викториналар уздыру; татар әкиятләрең һәм җырларын өйрәтү, татар биюләрен башкару, сыйныф газеталары чыгару, шагыйрьләр ,язучылар белән очрашулар һәм кызыклы кичәләр үткәрү; курчак театрына бару, күренекле шәхесләренең музейларына экскурсияләр оештыру аеруча әһәмиятле. Мондый чаралар аралашу осталыгын тагын да камилләштерүгә, аның нәтиҗәлелеген арттыруга китерә.

  Бу эш безнең мәктәбебездә яхшы куелган. Укучыларның эшчәнлекләрен әдәби кичәләрдә, үткәрелгән бәйрәмнәрдә күрәбез.


Китапхана
21.11.2014 16:20


68




12345
67890

# Уңышлы дәрес кагыйдәләре:

- укучыны бүлдермичә, аңа үз фикерен әйтеп бетерергә мөмкинлек бирү;
- параллель диалогларны булдырмау;
- укучыларга фикер йөртү өчен азык биреп тору;
- бирелгән сорауларны җавапсыз калдырмау;
- дәрестә фикер алышуны кул күтәрмичә генә алып бару;
- билге куйганда укучының эшчәнлеген мактарга, ә укучыны үзен түгел;
- билгене гадел куярга тырышырга, гаделсезлек, белгәнебезчә, конфликт тудыра

# Мәгълүмати коммуникатив технологияләрнең формалары:

- 1.Әзер электрон продуктларны куллану белем бирүнең сыйфатын яхшырта,күрсәтмәлелек принцибын ачык итеп тормышка ашырырга ярдәм итә.
- 2.Мультимедиалы презентацияләр куллану уку материалын истә калдырырга булыша.
- 3.Интернет челтәре ресурсларын куллану белем алуга кирәкле информацияне таба белергә һәм системага салырга ярдәм итә.

# Сөйләмдәге кимчелекләрне төзәтү

өчен тел төзәткечләр,тел шомарткычлар,шигырьләр,тизәйткечләр өйрәтү мөһим. Н.Исәнбәтнең “Балалар фольклоры”ында боларга киң урын бирелгән.

Мәсәлән:

Ка-ка-ка-күлдә бер бака,

Ку-ку-у-ул баканы ку,

Кы-кы-кы-күл бит анык.

Шигырьләр җиңел рифмалы,истә кала торган булырга тиеш